**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Первомайская ул., д.39, г. Лаишево, 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Беренче май ур., 39 нчы йорт, Лаеш ш., 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**2025 елның 13 нче ноябрь** **номер 20-РС**

# КАРАР

**Лаеш муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү буенча бердәм комиссия һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Бердәм аттестация комиссиясен төзү турында» 2022 елның 28 мартындагы 29-РС номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү буенча бердәм комиссия һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Бердәм аттестация комиссиясе эшчәнлеген камилләштерү максатларында Лаеш муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү буенча бердәм комиссия һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының бердәм аттестация комиссиясен төзү турында» 2022 елның 28 мартындагы 29-РС номерлы карарына 1 нче кушымта белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Бердәм аттестация комиссиясе составына (05.08.2024 № 62-РСномерлы карардагы соңгы үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) комиссия составыннан Р. Т. Гарифуллинны чыгарырга;

2) комиссия составына кертергә:

Нурмөхәммәтов Азат Әнәс улын - Лаеш муниципаль районы Советы Аппараты Җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү буенча бердәм комиссия һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының бердәм аттестация комиссиясен төзү турында» 2022 елның 28 мартындагы 29-РС номерлы карарына 2 нче кушымта белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш

муниципаль районы Бердәм аттестация комиссиясе составына (05.08.2024 № 62-РС соңгы үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) комиссия составыннан Р. Т. Гарифуллинны чыгарырга;

2) комиссия составына кертергә:

Нурмөхәммәтов Азат Әнәс улын - Лаеш муниципаль районы Советы Аппараты Җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары.

3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән)көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе А. Ә. Нурмөхәммәтовка йөкләргә.

**Муниципаль район Советы**
**рәисе-башлык вазифаларын башкаручы** **Т.П. Борһанова**